ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 36-2-45, факс: (84379) 36-2-45.

31 октябрь 2020 ел. №3

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар  Бурнашы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2021нче елда 300 сум күләмендә  үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? дигән  мәсьәлә буенча 2020нче елның 23нче октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Татар Борнашы авылында балалар мәйданчыгы төзү

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә - 454 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 231 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 231 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Татар Борнашы авыл җирлегендә халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип  танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылында  яшәү урыны буенча теркәлгән,  авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары карары белән билгеләнгән ташламалы категориядән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 300 сум күләмендә  үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны  түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме? – Татар Борнашы авылында балалар мәйданчыгы төзү дигән мәсьәләләрне хәл итү буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылы халык җыены нәтиҗәләрен Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче С. В. Бурукин